

# Рабит Батулла

Роберт Батулла (Роберт Мөхлис улы Батуллин) 1938 елның 26 мартында Татарстан АССРның Зәй районы Түбән Оложы авылында укытучы гаиләсендә туа. 1955 елда Биш Авылы урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, бер ел шул районның Кадер авылындагы җидееллык мәктәптә балалар укыта. 1956—1961 еллар да Мәскәүдә М. С. Щепкин исемендәге театр училищесында укый, аны тәмамлагач, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына эшкә җибәрелеп, ике ел актер хезмәтендә була, бер ук вакытта режиссерлык эше белән дә шөгыльләнә. 1963—1965 елларда Казан Курчак театрында һәм Казан телевидение студиясенең балалар өчен тапшырулар редакциясендә режиссер булып эшли. 1965 елның кезендә Татарстан Культура министрлыгы аны Мәскәүгә Театр институты каршындагы бер еллык Югары режиссерлык курсларына укырга җибәрә, аны тәмамлап кайткач, Р. Батулла ун елга якын башта Казан Курчак театрында, соңыннан Казан культура институтында режиссер-педагог һәм Курчак театрында баш режиссер була. 1977—1979 елларда ул янә Мәскәүдә: М. Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларда укый. Курсларны тәмамлап кайткач, театр училищесында укыта.
Р. Батулла әдәбиятның төрле жанрларында иҗат итә. Аның балалар өчен язган хикәяләре, мажаралы әкиятләре, шулай ук юмор-сатира жанрындагы язмалары, инсценировкалары, бер пәрдәле пьесалары, сценарийлары көндәлек матбугатта, телевидение экранында һәм Курчак театры сәхнәләрендә алтмышынчы еллардан күренә башлый. 1966 елда беренче китабы — «Исемем минем Дүрткүз» дип аталган маҗаралы повесть-әкияте басылып чыга. Хәзерге вакытта ул — дистәдән артык китап авторы.



# Батулла бабай әкиятләре

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Күңелле туй | 3:23 |
| 2. | Шапшакларны бака ялый | 2:29 |
| 3. | Тычкан уты | 2:31 |
| 4. | Карурманга бара Мөбәрәк | 2:42 |
| 5. | Атка атланган Шүрәле | 2:55 |
| 6. | Оча торган тиен | 4:53 |
| 7. | Такыя кигән Мөбәрәк | 10:34 |
| 8. | Елак әтәч | 1:52 |
| 9. | Әйлән-бәйлән уены | 2:37 |
| 10. | Чыбык ашату | 2:27 |
| 11. | Аю Әппәс | 3:08 |
| 12. | Салават күпере кайда йоклый | 7:13 |
| 13. | Әбү булган аягы | 3:41 |
| 14. | Терек-терек кырмыска | 3:54 |
| 15. | Очты-китте торналар | 3:58 |
| 16. | Балавыз | 4:41 |
| 17. | Колакчын Тафи | 5:31 |
| 18. | Яшел күбәләк | 4:26 |
| 19. | Җилкәнле башмак | 5:07 |
| 20. | Ике маэмай | 4:38 |
| 21. | Сак белән Сок кавышканда | 9:13 |
| 22. | Ачык авыз | 3:02 |
| 23. | Тургай | 2:24 |
| 24. | Гөлзадә әкияте | 12:01 |
| 25. | Су ияләре | 4:18 |
| 26. | Нурбәк әкияте | 2:45 |
| 27. | Баллы чәчәк | 4:16 |
| 28. | Чурык-чурык патша кызы | 4:44 |
| 29. | Әкәч белән Тәкәч | 1:18 |
| 30. | Озын телле кош | 4:42 |
| 31. | Ак песи, кара песи | 6:15 |


БАТУЛЛА
Әстәгъфирулла!
Батулла
Сююм-бике — царица казанская
БАТУЛЛА
МИРАДЖ
Киносценарии
БАТУЛЛА
КИЧЕР МИНЕ, ӘНКӘЙ
Рабит Батулла
ОДЕРЖИМЫЙ ТАНЦАМИ
Рабит Батулла
БАТУЛЛА
Тузга язмаган хәлләр
Рабит Батулла
Аю баласы Әппәс
Рабит Батулла
КЫЛДАН НЕЧКӘ, КЫЛЫЧТАН ҮТКЕН


РАБИТ БАТУЛЛА
КОЛАКЧЫН ТАФИ


СЫН-ЖУРАВЛЬ


Король птиц



Мин сабый чагымда очучы булырга хыялландым. Күзем һәм йөрәгемнең тиешенчә сәламәт булмавы бу уйдан ваз кичәргә мәҗбүр итте. Әти-әнием юлыннан, ягъни укытучылык юлыннан китәчәк түгелмен, дип ант иттем. Ходай миңа укытучылыкны насыйп кылган икән. Озак еллар укытучы булып эшләргә туры килде. Артистлыкка укыдым, язучы булып киттем. «Аксыл-сары чәчле хатынга өйләнәм!» — дип хыялландым, хатыным кап-кара чәчле, зәңгәр күзле булып чыкты. Аллаһы Тәгалә кемгә кем кирәклеген бик яхшы белеп тора икән.

Рәбит БАТУЛЛА

ИДЕЛ

# Тест сораулары

1.Рабит Батуллага быел ничә яшь тулды (иполнилось)?
 а) 80
ә) 82
б) 84

2.Р. Батулла ninди училищеда укый?
 а) Щепкин исемендәге
ә) Качалов исемендәге
б) Пушкин исемендәге

3.Ул Галиәсгар Камал театрында кем булып эшли?
 а) костюмер
ә) гример
б) актер

4. Язучы кемнәр өчен иҗат итә?
 а) балалар һәм әбиләр
ә) өлкәннәр һәм балалар
б) яшьләр һәм зурлар

5. Аның пьесалары кайда куела?
 а) күләгә (тень) театрында
ә) курчак театрында
б) бармак театрында

6. "Бию җене кагылган егет" әсәре кем турында (о ком)?
 а) Ирек Мөхәммәдов
ә) Майя Плисецкая
б) Рудольф Нуриев

7.Әдипкә нинди Мактулы исем (Похвальное звание) бирелде?
 а) Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе
ә) Театрның иң яхшы сәнгать эшлеклесе
Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе